ГЛАВА БОЛЬШЕМЕМИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Ул. Советская, д.62, с. Татарское Бурнашево,
422579

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
Олы МемиАВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ
Совет ур., 62 нче йорт, Татар Борнашы авылы,
422579

Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30-1-48.

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30-1-48.

11.11.2025 с. Большие Мемей № 2

Гражданнарның үзара салымын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6нчы октябрендәге131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 ст., «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге Татарстан Республикасы Законының 35 ст., Югары Ослан муниципаль районы Олы Мемиавыл җирлеге Уставының 24 ст. нигезендә,

КАРАР БИРӘМ:

1. Югары Ослан муниципаль районы Олы Меми авыл җирлегенең Олы Меми авылында халыкка үзара салым кертү буенча халык җыенының беренче этабын 2025 елның 26 ноябрендә 9 сәгать 00 минутка билгеләргә.
2. Югары Ослан муниципаль районы Олы Меми авыл җирлегенең Олы Меми авылында халыкка үзара салым кертү буенча халык җыенының икенче этабын 2025 елның 26 ноябрендә 10 сәгать 00 минутка билгеләргә.
3. Югары Ослан муниципаль районы Олы Меми авыл җирлегенең Олы Меми авылында халыкка үзара салым кертү буенча халык җыенының өченче этабын 2025 елның 26 ноябрендә 11 сәгать 00 минутка билгеләргә.
4. Халык исемлеген бүлүне территориаль билге буенча башкарырга.

1 этап: Олы Меми авылының Заречная, Исаевка урамнары халкы
2 этап: Олы Меми авылының Молодежная урамы халкы
3 этап: Олы Меми авылының Гаврилов Я.А., Үзәк урамнары халкы

5. Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Югары Ослан муниципаль районының Олы Меми авыл җирлегенең Олы Меми авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 2026 елда 600 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтүгә ризамы?

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Олы Меми авылындагы юлларны ремонтлау өчен, товарны билгеләнгән пунктка илтеп җиткерү юлы белән вак таш сатып алу):

«ӘЙЕ» «ЮК»

6. Халык җыеннарын үткәрергә:

1 этап: Олы Меми авылының Заречная урамындагы 15 нче йорт янында

2 этап: Олы Меми авылының Яшьләр урамындагы 18нче йорт янында

3 этап: Олы Меми авылының Гаврилов Я.А. урамындагы 45нче йорт янында

7. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында, шулай ук мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

Югары Ослан муниципаль районының
Олы Меми авыл җирлеге башлыгы Г.А. Фомина